# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2015 елның 30 декабре №23

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «җирле референдум үткәрүне оештыру турында» 2015 елның 28 декабрендәге 104 номерлы карары, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрүне оештыру турында»2015 елның 28 декабрендәге 22 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карары:

1. 2016 елның 6 мартына Зеелнодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2016 елда Карамалы Тау шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 150 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Җирлек торак пунктлары чикләрендә юлларны төзү, карап тоту һәм ремонтлау. | 120000 |
| 2. | Җирлек торак пунктларында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү, реконструкцияләү, алыштыру һәм ремонтлау. | 100000 |
| 3. | Җирлектәге төзекләндерү объектларын төзү һәм карап тоту. | 230300 |
| 4. | Җирлекнең янгынга каршы су белән тәэмин итү объектларын төзү һәм карап тоту. | 30000 |

«ӘЙЕ» «ЮК».».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Карамалы Тау шәһәр җирлеге, Беренче Май урамы, 70 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә тиеш.

**Җирлек башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ф.Н. Шәмсиев**